Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының утыз икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
карары

14 май 2020 ел № 267

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставы нигезендә, 2020 елның 12 маендагы ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен кушымта нигезендә электрон рәвештә расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов